| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**30.05.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 397** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 07 сентябрендәге 316 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 30 апрелендәге 290 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 07 сентябрендәге 316 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 23 статьяда:

4 пунктның 5 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;

6 нчы пунктның җиденче абзацында «18 процент» сүзен «41 процент» сүзләре белән алыштырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**